КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2022 ел, 16 март г.Казань № б-527

Татарстан Республикасы территориясендә ящур авыруы барлыкка килүне һәм таралуны булдырмау, эпизоотия чорында ящур авыруыннан авырулар санын, үлем санын һәм социаль-икътисадый зыянны киметү чараларын эшләү һәм гамәлдә тормышка ашыру максатларында:

1. Бу боерыкка теркәлгән 2022 – 2027 елларга Татарстан Республикасында ящур авыруы белән авыруны профилактикалау чараларының комплекслы планын (алга таба – План) расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына Планның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән кирәкле чаралар күрергә, шулай ук Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына, Кеше хокукларын саклау һәм кеше иминлеген яклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы (Татарстан) буенча идарәсенә, Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә, «Россия авыл хуҗалыгы үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларына – әлеге чаралар күрүне тәкъдим итәргә.

3. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин